**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№279**
**24.01.2020**

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча торак урын бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыймматләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча муниципаль торак фондындагы торак урыннарны бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем килешүләре буенча торак урын бирү максатында, 2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыймматләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәте – 10 465 сум 64 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 954 432 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1 908 864 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2 863 296 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 817 728 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 4 772 160 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 5 726 592 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 681 024 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 635 456 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев